ПРОЕКТ


ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планы проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашуга хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2013 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының 04.06.2020 ел № 58-670 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планын карау буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы) билгеләргә.

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру вакыты - 2024 елның 26 июленнән 2024 елның 25 июленә кадәр;

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

3.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

3.2. Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар башлануы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планы проектын һәм аңа мәгълүмати

материалларны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең барлык торак пунктларында да проектлар буенча экспозицияләр оештырырга.

Тәкъдимнәр, искәрмәләр кабул ителә:

1) Югары Ослан муниципаль районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ рәсми сайты аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә: Татарстан Республикасы, Югары Ослан ав., Чехов ур., 18, яисә Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетына Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Введенский Бистәсе авылы, Үзәк ур., 55 йорты адресы буенча;

3) җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналында язылу юлы белән.

3.4. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В.Осянин